**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 21 февраль | № 105

г. Казань

Дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 ел, 31 декабрь, б-2146 нчы боерыгы белән расланган Озак вакытлы чорга (2010 – 2020 елларга) «Россия автомобиль юллары» дәүләт компаниясе эшчәнлеге программасын тормышка ашыру кысаларында «Санкт-Петербург – Вологда – Казан – Оренбург – Казахстан Республикасы чиге» автомагистраленең «Баулы (М-5) – Шалты» участогын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 49, 55 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Автострада» ачык акционерлар җәмгыятенең Г.И.Алякин милкендә булган, карарга теркәлгән кушымтада күрсәтелгән 57,9376 гектар гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – җир кишәрлекләре) элемтә юллары, транспорт объектларын урнаштыру өчен, аларны урнаштыру буенча башка вариантлар булмаса, сатып алу юлы белән алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына билгеләнгән тәртиптә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

җир кишәрлекләренең сатып алу бәясен билгеләүне һәм аларның милекчесе белән тиешле килешүләр төзүне;

җир кишәрлекләренең тиздән алыначагы турында милекчегә хәбәр итүне;

бу карарны дәүләт теркәвенә алуны һәм теркәү үткәрелү турында, аның датасын күрсәтеп, милекчегә хәбәр итүне;

милекче җир кишәрлекләрен алу турындагы карар белән килешмәгән очракта, судка тиешле дәгъвалар кертүне;

сатып алынган җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алу үткәрүне.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына җир кишәрлекләренең сатып алу бәясен билгеләгәннән соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карарга теркәлгән кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләрен

Татарстан Республикасы милкенә сатып алу чыгымнарын финанслау күләме һәм чыганаклары буенча тәкъдимнәр кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\105.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 21 февраль, 105 нче
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле җир кишәрлекләре исемлеге**

| Т/с | Кадастр саны | Кишәрлекнең урнашкан урыны | Мәйданы, гектар |
|---|---|---|---|
| 1 | 16:11:090401:313 | Баулы муниципаль районы, Салихов авыл җирлеге | 7,9520 |
| 2 | 16:11:090402:139 | Баулы муниципаль районы, Салихов авыл җирлеге | 25,8316 |
| 3 | 16:11:090402:153 | Баулы муниципаль районы, Салихов авыл җирлеге | 5,9076 |
| 4 | 16:11:090402:155 | Баулы муниципаль районы, Салихов авыл җирлеге | 3,0828 |
| 5 | 16:11:050202:352 | Баулы муниципаль районы, Шалты авыл җирлеге | 6,45 |
| 6 | 16:11:050202:353 | Баулы муниципаль районы, Шалты авыл җирлеге | 6,45 |
| 7 | 16:11:050202:366 | Баулы муниципаль районы, Шалты авыл җирлеге | 2,2636 |
| Барлыгы | | | 57,9376 |